Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының утыз җиденче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

27 май, 2025 ел № 123

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 12 апрелендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карарына (Питрәч авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 октябрендәге 52 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 63, 2024 елның 29 маендагы 101 номерлы, 2025 елның 31 гыйнварындагы 119 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның 1.1 пунктчасында «13 990» санын «15 389» саннарына алмаштырырга;

1.2 пунктның 1.2 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

5 кушымтаның 3 пунктындагы 3.1 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

7 кушымтаның 6 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сөләйманов